ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**_2025 елның 30 июле_** **Чистай шәһәре** **№ _359_**

«Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 816 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 маендагы 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы, "Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 816 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 816 номерлы карары кушымтасында 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «төзелгән гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан

электрон формадагы гарызнамә юлының дөрес тутырылмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерүнең тәртибе турында гарызнамәнең электрон формасының үзендә үк мәгълүмати хәбәр аркылы кисәтелә».

1.2. «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 816 номерлы карары кушымтасында 1.5.1 пунктындагы 7 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә тиешле бина күпфатирлы йорт дип таныла».

1.3. Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 маендагы 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы, "Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты".

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары итеп йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов